КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 ноябрь г.Казань № 1072

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 06 сентябрь, 739 нчы карары белән расланган «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучыларны бүләкләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучыларны бүләкләү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 06 сентябрь, 739 нчы карары белән расланган «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучыларны бүләкләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агент - Вәкаләтле оешма белән төзелгән агент шартнамәсе нигезендә Россия Банкы түләү системасының тиз түләүләр сервисын кулланып «Халык инспекторы» системасы кулланучыларына түләүне гамәлгә ашыручы оешма.»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кулланучының банк счетына күчерүне гамәлгә ашыру шартлары белән ризалыгы булу.»;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Кулланучыга акчалата түләү Вәкаләтле оешма тарафыннан Органнардан алынган белешмәләр (реестрлар) нигезендә акчасыз рәвештә башкарыла.

Кулланучыга акчалата түләү Вәкаләтле оешма тарафыннан башкарыла, ә Россия Банкының түләү системасы тиз түләүләр сервисыннан файдаланганда - Агент тарафыннан административ хокук бозу турындагы эш карары законлы көченә кергән көннән алып 40 эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Кулланучының банк счетына акчалата түләүне күчерүне гамәлгә ашыру тәртибе Вәкаләтле оешма тарафыннан билгеләнә һәм «Халык инспекторы» системасында урнаштырыла.»;

4.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин